СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**26 декабрь 2023ел** **№117**

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**карары**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында урам исемен үзгәртү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына ярашлы рәвештә, үтенеч нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Шушмабаш авыл җирлеге территориясендәге Шушмабаш авылында Мәктәп урамын, үзгәртелгән урамда адрес номерларын саклап, Габделхәй Кәримов урамы дип үзгәртергә.

2. Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетына бер ай эчендә йөкләргә:

-Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларның урам исемнәре реестрына үзгәрешләр кертергә;

- исемен үзгәрткән урамда адрес атрибутикасын урнаштыруны тәэмин итәргә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыру буенча башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1Б йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, Татарстан урамы, 45 йорт адреслары буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

В. В. Сәгыйтов